МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.03.2023 Казан ш. № 02-15

«Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар биргәндә субсидия, субвенция, максатчан билгеләнешле башка бюджетара трансферт бирү турында уведомление җибәрү тәртибен раслау хакында» 20.02.2018 ел, № 02-17 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

«Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар биргәндә субсидия, субвенция, максатчан билгеләнешле башка бюджетара трансферт бирү турында уведомление җибәрү тәртибен раслау хакында» 20.02.2018 ел, № 02-17 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министр вазыйфаларын башкаручы М.Д. Фәйзрахманов

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының
«03» март 2023 ел
№ 02-15

боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар биргәндә субсидия, субвенция, максатчан билгеләнешле башка бюджетара трансферт бирү турында уведомление җибәрү тәртибен раслау хакында» 20.02.2018 ел, № 02-17 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

1. Боерыкта:

2 пунктны үз көчен югалаткан дип танырга;

3 пунктта «Министрлыкның Казначылык департаменты директоры урынбасарына» дигән сүзләрне «Министр урынбасарына» дигән сүзләргә алыштырырга.

2. Бу боерык белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар биргәндә субсидия, субвенция, максатчан билгеләнешле башка бюджетара трансферт бирү турында уведомление җибәрү тәртибендә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды идарәсе органына» дигән сүзләрдән соң «, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә» дигән сүзләрне өстәргә;

5 пунктның икенче абзацында «бюджет бүлеге тарафыннан» дигән сүзләрдән соң «Татарстан Республикасы бюджетын төзү һәм үтәүне оештыру бүлеге тарафыннан» дигән сүзләрне өстәргә;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең финанс органнары, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды идарәсе органы, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге Министрлык Уведомление җибәргәннән соң өч эш көне эчендә»АЦК-Финансы» программасында Уведомление алуны һәм аны раслауны тәэмин итә. Раслама электрон документ рәвешендә булдырылып, аңа Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең финанс органы, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды идарәсе органы, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге исеменнән эш итүгә вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куела.

Уведомлениене электрон рәвештә җибәрү һәм көчәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдалану нигезендә Уведомлениене алуны раслау өчен техник мөмкинлекләр булмаган очракта, Министрлык Уведомлениене булдыруны һәм җибәрүне, бу Тәртипнең 3 һәм 4 пунктларында күздә тотылган срокта, билгеләнгән тәртиптә имзаланган кәгазьдәге документ рәвешендә, тапшыру турында уведомление белән заказлы хат рәвешендә, хәл итә.».